КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 март г.Казань № 186

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларыннан файдалана алу мөмкинлеген һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне тәэмин итүне дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында

«Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль законның 5 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларыннан файдалана алу мөмкинлеген һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне тәэмин итүне дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 март, 186 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларыннан файдалана алу мөмкинлеген һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне тәэмин итүне дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

Министр;

министр урынбасары (дәүләт тикшерүендә тотуның тиешле өлкәсе өчен җавап бирүче);

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы урынбасары;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең төп киңәшчесе;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең төп консультанты;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең төп белгече-эксперты;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

инвалидлар белән эшләү бүлеге башлыгы;

инвалидлар белән эшләү бүлеге башлыгы урынбасары;

инвалидлар белән эшләү бүлегенең төп киңәшчесе;

инвалидлар белән эшләү бүлегенең төп консультанты;

инвалидлар белән эшләү бүлегенең төп белгече.

___